ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**17.02.2020** **Чистай шәһәре** **№ 78**

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының
2016 елның 22 апрелендәге
«Вазыйфаи затларга административ
хокук бозулар турында беркетмәләр
төзү вәкаләтләрен бирү хакында»
247 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Балигъ булмаганнарга тотрыксыз никотин булган продукцияне, никотин китерүнең электрон системаларын сатуны тыю һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 2019 елның 25 декабрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**Карар бирә:**

1. «Вазыйфаи затларга административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү вәкаләтләрен бирү турында» Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 22 апрелендәге 247 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 22 апрелендәге 247 номерлы карары белән расланган ТР КоАП административ хокук бозулар составлары исемлеген түбәндәге пункт белән тулыландырырга:

«2.16 статья - балигъ булмаганнарга тәмәке тартмый торган никотинсыз продукция, никотин китерүнең электрон системаларын сатуны тыюны бозу, шулай ук балигъ булмаганнарны тәмәкесез никотинлы продукция куллануга җәлеп итү».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат сайтында бастырып чыгарырга(pravo.tatarstan.ru) һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (chistopol.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе О.В. Заглядовага йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов